СПАС РАЙОНЫ ЯМБАКТЫ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕНЕН

ГРАЖДАННАР ЖЫЕНЫ КАРАРЫ

2024 елның 15 ноябрендәге 2 нче номерлы

Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Ямбакты авыл җирлегенең Ямбухтино торак пунктында 2025 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына, Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Ямбакты авыл җирлегенең Ямбакты торак пунктында гражданнар җыены

Карар кабул итте:

1.2025 елда Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Ямбухтино авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертергә.
2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:
- Ямбакты торак пунктында урам яктырту объектларын тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (энергия саклаучы яктырткычлар сатып алу);
- Санкциялэнмәгән чүплекләрне рекультивацияләү, (эш өчен килешү буенча түләү,)
- Традицион күмү урыннарын төзекләндерү (Ямбакты авылының 1 һәм 2 нче зиратлары территориясендә агач һәм куакларны кисү (килешү буенча эш өчен түләү); зират территориясен чабу( килешү буенча эш өчен түләү); ТРИММЕРЛАР һәм бензопиллар өчен ягулык-майлау материаллары сатып алу.
- Бензопила һәм триммерлар өчен запас частьләр сатып алу
- Кар чистарту өчен МТЗ-82 тракторына ягулык-майлау материаллары сатып алу.
- Елгаларны һәм күлләрне чистарту. («Урам күле " күлен чистарту, эш өчен килешү буенча түләү).
- Бөек Ватан сугышында һәлак булганнар хөрмәтенә куелган һәйкәлне реконструкцияләү һәм ремонтлау (Материалларны төзекләндерү, эш өчен килешү буенча түләү)
- Ямбакты авыл жирлеге. территориясен, авыл эчендәге юл кырыйларын чабу (килешү буенча эшләү), МТЗ-82 тракторы һәм триммерлар өчен ягулык-майлау материаллары сатып алу.

3. Ямбакты авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән гражданнар җыены нәтиҗәләрен игълан итәргә, Спас муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга (http:// spasskiy.tatarstan.ru), рәсми хокукый мәгълүмат сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 10 көн дәвамында.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,

Ямбакты авыл жирлеге башлыгы И.А.Галәветдинов